ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 май 2019ел № 2396

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Күп фатирлы йорттагы бүлмәләрне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә китерү өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 27 мартындагы 1631 нче карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3844 нче, 2018 елның 24 июлендәге 4158 нче, 2019 елның 6 февралендәге 556 нчы карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5.1 пунктның 3 абзацында «күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең ризалыгы буенча торак бүлмәләргә керергә һәм аларны тикшерергә» сүзләрен «күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләренең, социаль наем килешүләре буенча торак бүлмәләрне наемга алучыларның, социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүләре буенча торак бүлмәләрне наемга алучыларның ризалыгы буенча күп фатирлы йорттагы шундый бүлмәләргә керергә һәм аларны тикшерергә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1.5.2 пунктның 5 абзацын «милекчеләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә кадәр «күп фатирлы йорттагы бүлмә» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 2.5.3 пунктның 10 абзацын «әлеге йорттагы гомуми мөлкәтне» сүзләреннән соң «күп фатирлы йорттагы бүлмәләрне яңадан

планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин